КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 6 декабрь г.Казань № 1178

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында» 2020 ел, 30 сентябрь, 887 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында» 2020 ел, 30 сентябрь, 887 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 19 декабрь, 1159 нчы; 2021 ел, 27 гыйнвар, 28 нче; 2021 ел, 25 февраль, 95 нче; 2021 ел, 26 май, 375 нче; 2021 ел, 28 июль, 662 нче; 2021 ел, 13 сентябрь, 867 нче; 2021 ел, 3 ноябрь, 1045 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган 2021 елга социаль-көнкүреш хезмәтләре, социаль-медицина хезмәтләре, социаль-психологик хезмәтләр, социаль-педагогик хезмәтләр, социаль-хезмәт хезмәтләре, социаль-хокукый хезмәтләр, социаль хезмәтләрдән файдаланучыларның коммуникатив потенциалын арттыру максатларындагы хезмәтләр күрсәтүне кертеп, стационар формада социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә норматив чыгымнарда:

I бүлекнең 2 пунктында:

3 графада «636,27» саннарын «638,26» саннарына алмаштырырга;

4 графада «642,64» саннарын «644,63» саннарына алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 2.8 пунктча өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «2.8. | сроклы социаль хезмәтләр | 1,99 | 1,99»; |

әлеге карар белән расланган 2021 елга халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләренең гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү үзәкләре, гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү бүлекчәләре, өйдә социаль хезмәт күрсәтү бүлекчәләре тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә норматив чыгымнарның 1 пунктындагы 1.2 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга.

2. Бу карарның гамәле 2021 елның 10 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин